ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.03.2023 г. Заинск № 175

**«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 20 сентябрендәге 2078 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакындаында**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрнең (шәһәр округларының) башкарма комитетлары карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 11 февралендәге 20-09/2163 номерлы хатына, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 20 сентябрендәге 2078 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган (2014 елның 27 гыйнварындагы 157, 2014 елның 10 февралендәге 253, 2015 елның 12 октябрендәге 73, 2019 елның 04 сентябрендәге 472, 2021 елның 03 февралендәге 55, 2021 елның 06 апрелендәге 202 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибе» кушымтасының “Гомуми нигезләмәләр” бүлегендәге 1.3 пунктының беренче ике абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Компенсация алу хокукын билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 2019 елның 03 декабрендәге 1095 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны тәрбияләгән һәм караган өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләү өлешенә җан башына уртача керемнәре 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә өстәмә компенсация билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме түләү билгеләү турында гариза бирү аеннан алдагы 12 календарь айдагы гаилә әгъзаларының керемнәреннән чыгып исәпләнә.».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42